# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Югары Юшады торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

21 ноябрь 2025 ел № 2

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принңиплары турында» Россия Федерациясенең Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юшады авыл җирлеге" Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юшады авыл җирлеге Югары Юшады торак пунктында халык җыены

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юшады авыл җирлеге Югары Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, һәм СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Югары Юшады торак пунктында Владимиров урамы буенча юлны ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Юшады авыл җирлегенең мәгълүмат такталарында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлеге башлыгы И.Р.Ханов